**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «46 нчы гомуми урта белем бирү мәктәбе»**

elenaranko.ucoz.ru

мин татарча сөйләшәм!

elenaranko.ucoz.ru




Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле затлы тел.

Шәйхи Маннур.

elenaranko.ucoz.ru

***Март аенда 7нче сыйныф укучылары белән “Мин татарча сөйләшәм” акциясен дәвам иттек. Моның өчен үзебезнең микрорайонга чыктык. Урамнарда, кибетләрдә түштамгалар, сүзлекләр тараттык. Халыкны татар телендә сөйләшергә чакырдык. Халык безне бик ачык каршы алды. Рус телле балаларның татарча сөйләшүенә бик ихтирам белән карап, аларның сорауларына җавап бирергә тырыштылар. Телне белгән кешеләр балаларга сораулар биреп, аларны татарча сөйләштердек. Балалар алдан интервью, диалоглар өчен сораулар өйрәнеп куйганнар иде. Үзләренең татар телендә халык белән татарча аралаша алулары аларны канатландырды. Бигрәк тә яшьләр алар белән  яхшы аралашты.***

elenaranko.ucoz.ru

# Халык белән аралашуга әзерләнәбез




elenaranko.ucoz.ru



Акциябез дәвамында татарча белмәүчеләргә “Татар телендә синең 150 сүзең” китапчыклары һәм түштамгалар тараттык. Бу акция үткәрүгә эти-әниләребез дә бик зур ярдәм күрсәтте. Китапчыклар һәм түштамгалар алар ярдәмендә бастырылды.

elenaranko.ucoz.ru

**Безнең мәктәп урман янында урнашкан. Урманнан кайтучы чаңгычы да безнең белән тукталып сөйләште. Икетеллелекне бик хуплый икән.**



elenaranko.ucoz.ru

**Ашханәдә Наилә апабыз белән һәр көнне татарча сөйләшәбез. Ул безне бик ярата, тәмле ашлар белән сыйлый.**




elenaranko.ucoz.ru

***“Сокол” кибетендә эшләүче апалар безне елмаеп каршы алдылар,төрле сораулар биреп, рус телле балалар белән бик җанлы әңгәмә кордылар.***



elenaranko.ucoz.ru

# Урамдагы сәяхәтебез





elenaranko.ucoz.ru

*Сыйныф җитәкчебез Светлана Геннадьевна безнең белән татар телен өйрәнә!*





***Технология укытучыбыз Рамиль Мөнирович белән дә әңгәмәбез бик яхшы, күңелле үтте.***

elenaranko.ucoz.ru

***Туган телебезнең киләчәге-безнең кулда. Туган телебез горурланырлык булсын өчен, кулдан килгән кадәр тырышырга кирәк. Ә без моны эшләячәкбез. Киләчәк буыннарга татар телебезне саф һәм чиста итеп җиткерербез!***

elenaranko.ucoz.ru